4 бит **Хейтерларым юк әле** *Берәү генә язды*

5 бит **Җилдән җитез Альвина** *Әллә нинди трюклар ясый белә*

7 бит **«Өй-мәктәп-өй»** *Бер маршрут*

№35 (2227)

# Көмеш Кыңгырау

6+

Безнең белән үткән балачак
Күңелегездә мәңге калачак

7 сентябрь 2024 ел

podpiska.pochta.ru

Асия ЮНЫСОВА

## Көз мизгеле



Жир-әнкәбез чибәрләнгән,
Затлы киемен кигән.
Алма бизәкле күлмәге,
Миләшле яулык чөйгән.

Көмеш тоҗымлы калфагы
Бик килешә йөзенә.
Балан-миләш алкалары
Көздән бүләк үзенә.

Бар тереклек хәйран бүген,
Соклана Җир-әнкәгә,
Яшел хәтфә итәгенә
Сибә алтын тәңкәләр.

Өрәңгеләр кул чабалар,
Учлары – алтын яфрак.
«Мин дә күреп калыйм», – диеп,
Кояш чыккан ялтырап.



Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА рәсеме.



Лариса Шәемова фотосы.

# Гыйлем диңгезенә чумдылар...

**Әле генә балалар бакчасына йөри иде алар. Бүген Укучы дигән горур исемне йөртәләр. Шундый самими, ихлас, тиктормас һәм тырышлар. Гыйлем диңгезендә йөзәргә өйрәнәләр.**

Яр Чаллы шәһәрендәге 52нче мәктәпнең 1А сыйныфында кунакта булып кайттык әле. 29 укучы – 15 кыз һәм 14 малай укый анда. Укытучылары Марсилә Марс кызы Хәснетдинова 34 ел шушы мәктәптә белем бирә. Җиде сыйныф чыгарган икән инде ул.

Белемгә өйрәнү бишектән килә, диләр. Әле очарга гына өйрәнеп килә нәни укучылар – кошчыклар. Елдан-ел канатларыгыз ныгысын, дуслар. Зәңгәр күкләрне колачларлык гыйлем туплагыз. Туган телле, мәрхәмәтле булып үсегез.

*Җирнең нуры – кояш, кешенең нуры – белем.*

(Татар халык мәкале.)

№40 (2232)

# Көмеш Кыңгырау

Безнең белән үткән балачак
Күңелегездә мәңге калачак

6+


3 бит «Ак каурый»дан шигъри тәмлүшкәләр

7 бит Тренировка теш чистарту белән бер ул

8 бит «Жирнең дә томан дигән сөте бар»


12 октябрь 2024 ел


## Гәрәй РӘХИМ

### Көз йөри

Курайларда көз көйләрен уйнап,
Агачларны сары төскә буяп,
Куакларга җиләк-җимеш элеп,
Агач төпләренә гөмбә тезеп,
Урман буйлап алтын көз йөри.

Көшел-көшел бодай, арыш җыеп,
Саламнардан зур эскертләр куеп,
Кара җирне уҗым белән каплап,
Тракторлар белән гөрләп, шаулап,
Кырлар буйлап уңган көз йөри.

Балаларны мәктәпләргә дәшеп,
Аяк асларына яфрак чәчеп,
Тәрәзләрне яңгыр белән юып,
Күп кошларны җылы якка куып,
Урам буйлап наян көз йөри.



Рәсем freepik.com сайтыннан.


Язылу-2025

4-14нче октябрьдә газета-журналларга язылу декадасы уза.
«Көмеш кыңгырау»га ташламалы бәядән язылып калыгыз!
Ярты елга – 635,1 сум.
Бездән аерылмагыз!

РЕКЛАМА


# Вәлиевләр дәүләте

2024 ГАИЛӘ ЕЛЫ



Фото шәхси архивтан.

**Кеше бу дөньяга бәхетле яшәргә килә. Ә аны бәхетле итүчеләр янәшәсендә генә – гаиләсендә була. Гаилә – ул кечкенә бер дәүләт, ди халык мәкале. Аның үз кануннары, вазыйфалары, таләпләре шактый. Казан шәһәрендә яшәүче үрнәк гаилә – Гөлзар һәм Нияз Вәлиевләр, аларның балалары – Кәрим, Әнвәр, Ясминә һәм Сафия – әлеге язма геройлары. Гаилә елы уңаеннан, Вәлиевләр белән әңгәмә кордык. Әлеге гаиләгә – 17 яшь. Олы уллары Кәрим 10нчы сыйныфта, Әнвәр 6нчыда, Ясминә 5нчедә, ә кечкенәләре Сафия 2нче сыйныфта укый.**

– Абыйларым велосипедта йөрергә ярата, конструктор-компьютер белән мавыга. Ә без, кызлар, «Балалар филармониясе»нә вокал һәм хореографиягә йөрибез. Барыбыз да бассейнда йөзәргә яратабыз, шахмат уйныйбыз, – дип сөйләп китте әңгәмәдәшем Ясминә.

Дәвамын 4нче биттән укыгыз.

podpiska.pochta.ru

## Күңелдә калыр

Газиз туган җиркәем –
Гүзәл Пучы яклары.
Саф һавалы урманы –
Исе шикәрдән баллы.

Аның суы, инешләре
Бик шифалы, файдалы.
Аның чиксез басулары
Диңгездән дә бик олы.

Аның алтын уңышлары
Китерә бик күп файда.
Иге-чиге күренми дә –
Кырларга барып кара.

Аның олы күлләрендә
Балыклар ялт-йолт килә.
Су буенда шыбыр-шыбыр
Камышлар гүя көлә.

Авылымны һич онытмыйм,
Мәңге күңелдә калыр.
Аллы-гөлле матур хисләр
Җылы нур булып тамар.

**Габделкәрим ХАФАЕВ,**
*Актаныш районы,*
*Пучы урта мәктәбе,*
*7А сыйныфы.*

## Онытмамын...

Әниемнең җылы кочагын
Алыштырмам эссе җәйләргә.
Мәхәббәте мәңгелек аның,
Рәхәт мизгел сагынып сөйләргә.

Әниемнең назлы карашы
Җылыта бит, яннан китсә дә.
«Тәүфыйклы бул, балам, тормышта!» –
Онытмамын, күптән әйтсә дә.

**Дамир ГЫЙЛЬФАНОВ,**
*Мөслим районы, Мари Буләр мәктәбе,*
*9нчы сыйныф.*

**КҮҢЕЛЕМДӘ ШИГЫРЬ ТУДЫ**



## Әйтче, Көзкәй!

Бирче җавап, Көзкәй, син,
Минем шушы сорауга.
Әйтче, зинһар, ни өчен
Син һәрвакыт елауда?

Юк йөзеңдә елмаю,
Ни өчен син көлмисең?
Кояш белән дуслашмыйсың,
Әйтче, зинһар, ни өчен?

**Әмир ХАТЫЙПОВ,**
*Чаллы шәһәре, 54нче гимназия,*
*6нчы сыйныф.*

# Аллы-гөлле матур хисләр Җылы нур булып тамар!

## Менә шундый мич

Авылга кайтабыз еш,
Ерак юлларны үтеп.
Ишек ачкач та, йортта
Мич тора безне көтеп.

Ничә ел тора монда?
Ә үзе һаман ап-ак.
Без шәһәрдә булганда,
Йортны тора ул саклап.

Пешерә безгә дустым
Коймак, бөккән һәм шулпа.
Шундый тәмле пешерә –
Телне йотарлык була!

Утын салабыз мичкә –
Өебезне җылыта.
Анда изрәп йоклап киту –
Бәхет үзе ләбаса.

Мич өстендә уен уйнап
Үткәрәбез без кичне.
Плитәләр дә, карават та
Алыштырмас һич мичне!

**Руслан ЛОГИНОВ,**
*Чаллы шәһәре, 52нче мәктәп,*
*8нче сыйныф.*



## Кочакка сыймас кабак

Әбиемнең бакчасында
Үскән шундый зур кабак.
Ничек алып керергә дип,
Тордык шаккатып карап.

Җыйнаулашып тәгәрәттек
Ишегалдына җайлап.
Кичен бәлеш пешердек без,
Ашадык аны майлап.

Тәмле генә түгел әле,
Файдалы да ул кабак.
Мактый-мактый ашадык та,
Туйды бүгенгә тамак.

Сары кабак – көзге байлык
Быел бигрәк тә уңган:
Ай үсәсен көн үскәндәй,
Кочакка сыймас булган.

**Айсылу ИЛЬЯСОВА,**
*Чаллы шәһәре, 14нче гимназия,*
*8А сыйныфы.*

## Өлкәннәр көне

1 октябрь

**Актаныш районы Пучы урта мәктәбе укучыларының шигъри юлларында – ихлас котлау һәм рәхмәт хисләре.**

* * *

Рәхмәт сиңа, әбекәй,
Безне үстергән өчен.
Мин яратам сезне, диеп,
Гел сөеп торган өчен.

**Азалия ЗАКИРОВА,**
*9нчы сыйныф.*

* * *

Сезнең тормыш – олы бер тарих,
Күпләр өчен үрнәк алырлык.
Рәхмәт сезгә ихлас күңелдән,
Сезнең хезмәт – безгә горурлык.

**Исламия ГАЛИӘХМӘТОВА,**
*9нчы сыйныф.*

* * *

Картаям, дип, һич тә борчылма,
Өлкәннәрдә – акыл, сабырлык.
Ярдәм кирәк булган чакларда
Әле дә син бар киңәш алырлык.

**Ильвина САБИРОВА,**
*10нчы сыйныф.*

## Көзләр – шатлык ул

Ямьле җәйгә алмашка
Килде моңсу көзләр.
Урман, болын, кырларга
Инде алтын төсләр.

Җылы якка очып китте
Рәт-рәт булып кошлар.
Озакламый килеп җитәр
Кар-буранлы кышлар.

Кояш инде җылы нурын
Сибә әз-мәз генә.
Мул уңыштан авыз иткәч,
Күңелләр сөенә.

Юк, көзләрем сагыш түгел,
Шатлык ул күңелдә.
Байлык-муллык тулып торса
Табыннар түрендә.

**Җәмилә ВИЛДАНОВА,**
*Чаллы шәһәре, 3нче мәктәп,*
*7Б сыйныфы.*



*Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА рәсемнәре.*

podpiska.pochta.ru



ЯШЕЛ УТ

# Балалар – тимерьюлчы?!





**Әмир ЯМИЛЕВ,**
*«Будильник» телеканалының махсус хәбәрчесе*

*(Ахыры. Башы беренче биттә.)*

Иң элек кечкенә депода урнашкан составларга игътибар иттек. Монда яңа тепловоз тора. Мин, машинист буларак, аның кабинасына кереп, төрле бүлекләр белән таныштым. «Ай-һай, моның барысына да өйрәнергә...» – дип уйлап куйдым.

Аннары безгә пассажирлар залының икенче катындагы диспетчер бүлмәсен күрсәттеләр. Анда бер кыз белән малай утыра. Поезд уздыра торган пульт, барлык тимер юллардагы кебек чын зур табло тора. Шуңа карап, диспетчер машинистка кайчан составны җибәрергә, кайчан туктатырга кирәклеген әйтә. Биредә эшләүче 4нче курс укучылары Анна Ржнева һәм Артем Ефремов безне тимер юл серләре белән таныштырып киттеләр.

Соңыннан, билетлар алып, без поездга утырдык һәм «Яшьлек» станциясеннән «Изумрудная» станциясенә юл алдык. Алар арасында ике тукталыш бар – «Урман аланы» һәм «Стадион», дип атала. Монда перронга чыгып, саф һава сулап керергә була. Сәяхәтебез нибары 30 минут кына барса да, без үзебезне чын пассажирлар сыман хис иттек. Вагонга кергән төрле тимер юл «эшчеләре» – малайлар-кызлар белән таныштык.

Кире «Яшьлек» станциясенә кайткач, безне балалар белем ала торган зур корпуска алып киттеләр. Анда тимер юл белән бәйле һөнәрләргә өйрәтүче бүлмәләр белән танышып уздык. Шунысы бик сөенечле: кая гына керсәк тә, һәр кабинетта тимер юлчыларның программалары белән компьютерлар тора. Димәк, һәрбер укучы, үзенә кызыклы һөнәр сайлап, тимер юл мәктәбендә рәхәтләнеп белем алырга мөмкин. Аннары янәшә урнашкан тимер юл транспорты техникумында укуын дәвам итә ала. Киләчәген тимер юлчы һөнәре белән бәйләргә теләүчеләр өчен бик шәп бит, дуслар!



### Кыскача

*Балалар тимер юлы аларның күңелен күрү өчен генә түгел, ә тимер юл хезмәткәре һөнәре белән якыннан танышу өчен эшләнгән.*
*Октябрьдән мартка кадәр балалар теоретик белем алалар, җәй айларында махсус практика узалар.*
*Ел саен биредә 700ләп яшь тимерьюлчы һөнәри белем ала, шуларның 100-120се танышлыкка ия була.*

*И.Гыйләҗетдинов фотолары.*





podpiska.pochta.ru

ӘКИЯТНЕ ҮЗЕБЕЗ ЯЗАБЫЗ

# Ике дус



Борын-борын заманда яшәгән, ди, булган, ди, бер Кәҗә бәтие. Аның Куян дусты булган икән. Алар еш кына бергәләшеп сөйләшеп утырырга яратканнар. Куян үзенең урманда ничек итеп көн күрүе турында сөйләгән. Кәҗә бәтие дә аннан калышмаган. Сарайда ничек яшәвен бәян иткән. Шулай көн артыннан көн үткән.

Көннәрнең бер көнендә Куян Кәҗә бәтиенә:

– Син, Кәҗә бәтие, иркә яшисең: җылыда торасың, сине хуҗа абыең ашата, эчертә. Сине иркәлиләр, сиңа рәхәт, – дип әйткән, ди.

– Юк, Куян дустым, син дөрес уйламыйсың. Мин көнозын ябык урында торам, ә син иректә яшисең, – дип Кәҗә бәтие каршы килгән.

– Иректә булсам да, минем тормышым һәрвакыт куркыныч астында. Ничә тапкырлар инде миңа төлкеләрдән, бүреләрдән качарга туры килде. Аучының мылтыгыннан да чак котылып калдым. Мине бары тик житез аякларым һәм яхшы ишетә торган колакларым гына коткарып калды, – дигән куян.

– Синең кебек әзерне ашап, корсак симертеп кенә ятмыйм мин! – дип тә өстәп куйган.

Куянның бу сүзләренә Кәҗә бәтие үпкәләгән. Алар бер-берсенең хәлен аңлый алмаганнар. Куян урманына кайтып киткән, Кәҗә бәтие абзарына кереп яткан.

Көннәр, атналар, айлар үткән. Куянның берүзенә генә ямансу булган. Ул дустын сагынган. Кәҗә бәтиенә авыр сүзләр әйткәне, рәнҗеткәне өчен аннан гафу үтенергә киткән. Абзар янына килеп, дустын чакырыйм дисә, анда Кәҗә бәтиенең тиресе генә аунап ята икән. Куян үзенең соңарганын аңлаган һәм бик нык үкенгән. Моннан соң беркайчан да дусларын рәнҗетмәскә сүз биргән.

**Ризван МИРЗАЯНОВ,**
*Чаллы шәһәре,*
*18нче мәктәп, 5А сыйныфы.*
*Автор рәсеме.*



*Фото freepik.com сайтыннан.*

**Эчлек өчен:** *кабак – 300 гр; эремчек – 350 гр; каймак – 100 гр; шикәр комы – 5 аш кашыгы; ванилин – бер чеметем; желатин – 15 гр.*


**Камыр өчен:** *печенье – 100-120 гр; ак май – 50 гр; чикләвек – 50 гр.*

Печенье, чикләвекне ваклап, ак май кушабыз. Шуны савытның төбенә җәябез. Кабакны турап, духовкада йомшарганчы пешерәбез.

Кабак суынгач, эремчек, каймак, шикәр комы, ванилинны кушып, блендер белән изәбез.

Желатинны 60 мл суга салып күпертәбез һәм плитәдә җылытып алабыз. Кайнатып чыгарырга ярамый. Желатинны эчлеккә салып, яхшылап болгатабыз да печеньелы камыр өстенә салабыз һәм суыткычка куябыз. Чизкейк 7-8 сәгатьтә әзер була. Тәмле булсын!

## КРОССВОРД




**Вертикаль буенча:**
1. Муенны салкыннан саклый.
2. Тамчылар «төркеме».
4. Буйлы-буйлы зур җиләк.
5. Аларны күзен саныйлар.
6. Көзнең беренче ае.
10. Көздән соң җитә.
12. Яфраклары бишпочмаклы агач.

**Горизонталь буенча:**
3. Агачларның күлмәге.
7. Дюймовочкага ярдәм иткән кош.
8. Җылы түгел.
9. «... ачы шул, балам.»
11. Золушканың арбасы.
13. Чебеннеке дә бар, аюныкы да.
14. Кар турында «сөйләргә» яратучы кош.

Ләйлә Абдуллина төзеде.

**Җавап. Вертикаль буенча:** 1. Шарф. 2. Яңгыр. 4. Карбыз. 5. Чебн. 6. Сентябрь. 10. Кыш. 12. Өрәнгә. **Горизонталь буенча:** 3. Яфрак. 7. Карлыгач. 8. Салкын. 9. Балан. 11. Кабак. 13. Гөмбә. 14. Карга.

Узган сандагы япон кроссвордының җавабы



podpiska.pochta.ru
chelny-rt.ru
vk.com/komesh
t.me/chelny_rt
KOMESHKINGIRAY

Безгә языгыз: komesh_k@list.ru

Көмеш кыңгырау
республика балалар һәм яшүсмерләр газетасы
«ТАТМЕДИА» АҖ
Баш мөхәррир вазыйфаларын башкаручы
Л. Ш. ЯРУЛЛИНА
Тел. (8552) 54-00-27

Гамәлгә куючы: **«Татмедиа» АҖ**
**Редакция адресы:** 423827, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Яшь Ленинчылар бульвары, 9нчы йорт (27/19).
**Электрон адрес:** komesh_k@list.ru
**Нәшер итүче:** «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2нче йорт.

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 29нчы гыйнварында ПИ № ФС 77 - 77669 саны белән теркәлде. «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте тарафыннан оештырылды.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.

ТАТ МЕДИА
6+
1996 елдан чыга

Газета атнага бер, шимбә көнне чыга.
Заказ-наряд №8572
**Индекслар:**
Татарстанда – П2370
Россиядә – ПА435
Бәясе ирекле.
Тираж – 1976
№41 (2233)
Чыгу көне: 19.10.2024

Редакциянең фикере авторларның фикеренә тәңгәл килмәскә мөмкин.
Редакциягә килгән хатлар рецензияләнми, кире кайтарылмый.
Реклама белдерүендәге мәгълүмат өчен реклама бирүче җаваплы.
«Көмеш кыңгырау»дан алынган язмаларны редакциядән язма рөхсәт алган очракта гына басып чыгарырга мөмкин.

podpiska.pochta.ru